КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 15 сентябрь г.Казань № 833

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1064 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 10 март, 204 нче; 2012 ел, 28 май, 425 нче 2012 ел, 25 август, 737 нче; 2013 ел, 14 ноябрь, 874 нче; 2014 ел, 7 июнь, 389 нчы; 2016 ел, 13 август, 557 нче; 2016 ел, 30 декабрь, 1050 нче; 2017 ел, 27 ноябрь, 912 нче; 2018 ел, 12 май, 352 нче; 2018 ел, 29 октябрь, 956 нчы; 2019 ел, 15 гыйнвар, 2 нче; 2019 ел, 19 июль, 605 нче; 2020 ел, 28 апрель, 344 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Функцияләр

3.1. Үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашыра:

үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре, аттракционнарның техник торышы һәм аларны эксплуатацияләү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге (03.02.05*);

урамнан тыш транспортны техник эксплуатацияләү кагыйдәләренең һәм тапшырылган вәкаләтләр чикләрендә урамнан тыш транспорттан файдалану кагыйдәләренең үтәлешенә федераль дәүләт контроле (03.03.07*).

3.2. Татарстан Республикасының Үзйөрешле машиналар һәм техниканың башка төрләре техник торышына күзәтчелек итү идарәсе үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән дәүләт финанслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.02*);

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы белән юстиция өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.03*);

Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы белән түбәндәге функцияләрне гамәлгә ашырганда:

цифрлаштыру белән идарә итү (01.15*);

элемтә белән идарә итү (03.04*);

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән мәгариф белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.05*);

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы белән сәламәтлек саклау белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.02*);

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән авыл хуҗалыгы белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.02*);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгы белән табигать ресурларыннан файдалану, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.06*);

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән гражданнар оборонасы, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәткәндә һәм бетергәндә, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (02.01*);

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белән транспорт һәм юл комплекслары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (03.03*);

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (04.04*);

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән Татарстан Республикасы милкендәге мөлкәт һәм җир ресурлары белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.07*);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән хезмәт белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.13*);

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән социаль-икътисадый программалаштыру функциясен гамәлгә ашырганда (01.01*);

Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты белән бәяләрне (тарифларны) җайга салу функциясен гамәлгә ашырганда (01.08*);

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты белән Татарстан Республикасы ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру функциясен гамәлгә ашырганда (03.05.04*);

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты белән архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда (01.17*).»;

4.1 нче пунктта:

җиденче абзацта татар текстында «теркәлгән» сүзе үзгәрешсез кала, «, аттракционнарга» сүзен төшереп калдырырга;

егерме дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«техник тикшерү үткәрүне оештыру буенча чаралар күрү һәм Татарстан Республикасы территориясендә техник карау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыру;».

2. Бу карарның 1 нче пунктындагы егерме тугызынчы абзацы 2021 елның 1 мартыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин